КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 июль г.Казань № 594

«Республика психологик-медицина-педагогик консультациясе» дәүләт казна учреждениесе төрен үзгәртү һәм аның исемен алыштыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика психологик-медицина-педагогик консультациясе» дәүләт казна учреждениесе төрен аның төп эшчәнлеге максатларын саклап үзгәртү һәм исемен «Үзәк психологик-медицина-педагогик комиссия» республика психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – комиссия) итеп алыштыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

комиссияне гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә комиссия мөлкәте исемлеген Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

ел саен комиссия өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен расларга;

60 көн эчендә «Республика психологик-медицина-педагогик консультациясе» дәүләт казна учреждениесе уставына үзгәрешләр кертергә, аны дәүләт теркәвенә алуны Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

3. Комиссия тарафыннан дәүләт йөкләмәсенең үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга каралган акча чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү

тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр бирергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 2 нче, 4 нче пунктларын үтәгәннән соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларына аларны бу карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр эшләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин